РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 27 » ноябрь 2017ел. № 473-п

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының 2016 елның 28 гыйнварындагы
33-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклану белән тәэмин итү турында" 2016 елның 28 гыйнварындагы 33-п номерлы карарына (алга таба – карар тексты буенча) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарны киләсе редакциядә 3.1 һәм 3.2. пунктлары белән тулыландырырга.

«3.1. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – ЕГИССО) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга ярашлы рәвештә куллану аша күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

3.2. Әлеге карарда күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә ЕГИССОны куллану һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга ярашлы рәвештә алынырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм ТР Буа муниципаль районының рәсми сайтында: http://buinsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның 2018елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Н.Садретдиновага йөкләргә.

ТР Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Р. Камартдинов